РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«25» март 2020 ел Олы Кайбыч ав. № 220

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

РФ Хөкүмәтенең 2010 елның 26 февралендәге «Норматив хокукый актларның һәм норматив хокукый актлар проектларының коррупциягә каршы экспертизасы турында» 96 номерлы карары («Норматив хокукый актларның һәм норматив хокукый актлар проектларының коррупциягә каршы экспертизасын уздыру кагыйдәләре», «Норматив хокукый актларның һәм норматив хокукый актлар проектларының коррупциягә каршы экспертизасын уздыру методикасы» белән берлектә) нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру тәртибе турында» 2015 елның 21 августындагы 291 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру тәртибе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

7 пунктта «яисә рәсмиләштерү кагыйдәләрен бозып» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http:/ kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча рәсми сайтында һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында» бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Кайбыч муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесе Р.Г.Айзатулловага йөкләргә.

Совет Рәисе А.И.Рәхмәтуллин